**Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карары**

**20.06.2018 ел** **№ 511**

**Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф оешмаларының күренекле сәләтләрен күрсәткән укучыларын һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында**

2012 елның 29 декабендәге 273 –ФЗ номерлы “Россия Федерациясендәге мәгариф турындагы” Федераль закон, Татарстан Республикасының 2013 елның 28 июлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән “Мәгариф турындагы” Татастан Республикасы Законы, районның “2014-2018 елларга Кама Тамагы муниципаль районының сәләтле балаларына һәм аларның остазларына ярдәм итү” максатлы программасы нигезендә , Кама Тамагы муниципаль районының белем бирү оешмаларының һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренең предмет олимпиадаларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, бәйгеләрдә, спорт ярышларында сәләтләрен күрсәткән укучыларын бүләкләү максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф оешмаларының күренекле сәләтләрен күрсәткән укучыларын һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә Кама Тамагы муниципаль районының белем бирү оешмаларының һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренең күренекле сәләтләрен күрсәткән укучыларына һәм аларның остазларына, матди стимул бирү өчен, акчалата ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.
3. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 маендагы “Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф оешмаларының күренекле сәләтләрен күрсәткән укучыларын һәм аларның остазларын кызыксындыру чаралары турындагы” 548 номерлы Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.
4. . Түбәндәге карарны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х.Хәбибуллловага тапшырырга.

**Җитәкче** **Р.В.Михеев**